**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ «РЕСПУБЛИКА ОЛИМПИАДА ҮЗӘГЕ» ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

http://роцрт.рф

# 2−6 нчы сыйныф укучылары өчен «Татарча өйрәнәм» Республика олимпиадасы НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## Гомуми нигезләмә:

2−6 нчы сыйныф укучылары өчен татар теленнән «Татарча өйрәнәм» Республика олимпиадасы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Республика олимпиада үзәге» Дәүләт автоном белем бирү учреждениесе тарафыннан оештырыла һәм уздырыла.

## Олимпиаданың максаты һәм бурычлары:

− сәләтле балаларны ачыклау һәм барлау, аларның иҗади мөмкинлекләрен үстерү;
− татар телен туган тел һәм чит тел буларак өйрәнүгә кызыксыну уяту;
− укучыларның гомуммәдәни белем дәрәҗәләрен арттыру.

## Уздыру урыны:

Олимпиада Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Республика олимпиада үзәге» Дәүләт автоном белем бирү учреждениесе базасында уздырыла. Адресы: Казан шәһәре, Социалистическая урамы, 5 нче йорт («Авиатөзелеш» метро станциясе).

## Олимпиадада катнашучылар:

Гомуми белем бирү оешмаларының катнашу теләге белдереп теркәлгән һәм оештыру взносы түләгән 2−6 сыйныф укучыларына олимпиадада катнашу рөхсәт ителә.

## Олимпиадада катнашу шартлары:

- http://роцрт.рф урнаштырылган Олимпиада Нигезләмәсен һәм Шартнамәне игътибар белән укырга кирәк.
- Катнашучы яки аның законлы вәкиленең олимпиадада катнашуга гариза биреп, оештыру взносын түләве, катнашучының шәхси мәгълүматларын (катнашучының исеме, фамилиясе, әтисенең исеме, укыган сыйныфы һәм белем бирү оешмасы, электрон адресы; педагогның исеме, фамилиясе, әтисенең исеме) эшкәртүгә рөхсәт бирүе дип кабул ителә.

- http://роцрт.рф сайтыннан оештыру взносын түләү өчен квитанция үрнәген күчереп алырга кирәк.
- 380 сум күләмендә оештыру взносын түләү зарур.
- 2021 нче елның **21нчы октяберенә** кадәр гариза бирергә кирәк. Моның өчен http://роцрт.рф сайтында теркәлергә, түләгән квитанциянең күчермәсен дә теркәргә кирәк.
- **25нче октябрь** көнне 17.00дән соң http://роцрт.рф сайтында Олимпиаданы уздыру графигы белән танышырга мөмкин булачак.
- Олимпиада 2021нче елның **30нчы октяберендә** уздырыла. Оештыручы, чарада катнашырга теләк белдерүчеләр саныннан чыгып, олимпиаданы үткәрү вакытын үзгәртергә хокуклы.

**Республика олимпиада оештыру үзәге тарафыннан, олимпиада үткәрү вакытында коронавирустан саклану чараларын көчәйтү өчен, түбәндәге санитар- эпидемиологик таләп-кагыйдәләр билгеләнә**:
-социаль дистанцияне күрсәтүче махсус тамгалар булдыру;
-олимпиадага килүче укучыларның контактсыз рәвештә тән температурасын тишкерү ( тән температурасы тиешле нормадан арткан яисә ОРВИ,ОРЗ, ГРИПП симптомнары күзәтелгән очракта оештыручыларны һәм катнашучыларны кире кайтару);
-озата килүчеләрдә һәм укучыларда махсус битлекләр булуын таләп итү.

Аудиториядә эшне оештыруга таләпләр:

- укучыларны “зигзаг” рәвешендә утырту;
- ким дигәндә 1,5 метр ераклыкны саклау;
- кулларны даими рәвештә антисептик сыекчалар белән зарарсызландыру;
- бүлмәләр, коридорлар ике сәгать саен юешләп җыештыру, антисептик чаралар белән эшкәртү һәм җилләтү.

## Олипиаданы уздыру:

Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен һәм рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар һәм рус төркемнәре укучылары өчен олимпиада биремнәре бер эчтәлектә бирелә.

**1 нче бирем.** Текст өстендә эшләү. Һәр укучы мөстәкыйль эшли. Катнашучыларга махсус рәвештә текст бирелә. Текстны укырга һәм тескт буенча бирелгән 3 сорауга җава бирү сорала. Текст белән эшләү өчен 20 минут вакыт бирелә.

**2 нче бирем.** Катнашучыларга грамматик биремнәрне үтәргә тәкъдим ителә, җавапның дөрес вариантын сайлап алу сорала, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, мәкаль-әйтемнәрне дөресләп язарга кирәк була. Авазлар һәм хәрефләрне дөрес итеп сайлап алу, сүзләрне тамыр һәм кушымчага дөрес билгеләү сорала. Шулай ук сәнгать әдәбиятын белү буенча биремнәр үтәргә тәкъдим ителә, мәсәлән, геройларны атарга, дөрес авторны сайларга. Олимпиадада шулай ук логик биремнәр дә бар, ребусны чишү, кроссвордны хәл итү кебек биремнәр дә була.

*Биремнәр, катнашучыларның яшь үзенчәлеген исәпкә алып, мәктәп программасы нигезендә төзелә.*

## Олимпиадага нәтиҗәләр чыгару:

Эшләр тикшерелгәч, барлык баллар исәпләнеп, протокол тутырыла. Һәр параллельдә катнашучыларның гомуми җыйган баллары рейтингы буенча нәтиҗә чыгарыла. Олимпиада нәтиҗәләре **22нче ноябрьгә** кадәр http://роцрт.рф сайтына эленә.

- Максималь баллның 85 проценттан артыграгын җыйган катнашучылар **Җиңүче** исеменә лаек була. Максималь баллның 65 процентыннан артык җыйган катнашучылар. **Призёр** исеменә лаек була.
- Олимпиаданың җиңүчеләре, призёрлары диплом белән бүләкләнә, калган укучылар җыйган баллары күрсәтелгән катнашучы сертификаты ала.

**Олимпиаданың финанс тәэмин ителеше:**

Матди яктан олимпиада катнашучылар тарафыннан тәэмин ителә. Взнос банк реквизитлары буенча күчерелә һәм жюри әгъзаларының хезмәтенә түләүгә, оештыру чыгымнарына, бүләкләү фондына һ.б. тотыла.

**«Татарча өйрәнәм»**

*Катнашучылар өчен оештыру взносы күләме:*
380 сум + банк комиссиясе.
Акча түләгән катнашучы Олимпиадага килмәсә, оештыру взносы кайтарылмый.

**Элемтә өчен мәгълүмат:**

«Татарча өйрәнәм» Республика олимпиадасының оештыручысы − Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Республика олимпиада үзәге» Дәүләт автоном белем бирү учреждениесе.

Адресы: Казан шәһәре, Социалистическая урамы, 5нче йорт («Авиатөзелеш» метро станциясе).

Электрон почта адресы: rocrt.rf@mail.ru
Тел. (843) 590-36-59